ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

« 11» ноябрь 2022 ел — №22

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы,

Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге 2022 елның 26 нче октябрь 1 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче Отарка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең Отарка торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында " 2022 елның 26 октябрендәге 2 номерлы карары»

Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге 2022 елның 26 нче октябрь 3 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче“Пятилетка» совхоз торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең совхоз “Пятилетка” торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында " 2022 елның 26 октябрендәге 4 номерлы карары»

к а р а р  б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитеты житәкчесе /И.И.Фазылов /

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11 ноябрь 2022 ел, санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2023 елның 28 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки

https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының 11 ноябрь 2022 ел,
3 санлы карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме)*

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
___________________________________________________________________
Адрес: __________________________________________________________
Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2023 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2023 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр 500 сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: _________________________________________________
Кабул итүче як банкы БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП _________________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _________________ _______________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**
______________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. _______________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
«__» _______________ 20__ г. _____________________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*